КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 13 июнь г.Казань № 711

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 28 март, 233 нче карары белән расланган Муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 28 март, 233 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 5 август, 646 нчы; 2022 ел, 6 июнь, 521 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның дүртенче абзацында «хисап» сүзеннән соң «кварталыннан» сүзен өстәргә;

3 пунктта «ай саен» сүзләрен «квартал» сүзенә алмаштырырга;

6 пунктта:

беренче абзацта «аена» сүзен «кварталына» сүзенә алмаштырырга;

«а» пунктчасында:

дүртенче абзацта «аена» сүзен «кварталына» сүзенә алмаштырырга;

бишенче абзацта «аена» сүзен «кварталына» сүзенә алмаштырырга;

«б» пунктчасының өченче абзацында «аена» сүзен «кварталына» сүзенә алмаштырырга;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә шәһәр округының, муниципаль районның финанс органына ачылган шәһәр округы, муниципаль район бюджетының бердәм счетына күчерелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин